КАБУЛ ИТҮ

# Район башлыгына – үтенеч-гозер белән



*Район башлыгы Разиф Кәримов зәйлеләрне шәхси мәсьәләләр буенча атна саен кабул итә. Шул ук вакытта ул аена бер мәртәбә "Бердәм Россия" сәяси партиясенең Зәй бүлеге политсоветы секретаре сыйфатында да кабул итү үткәрә.*

Әлеге чара гадәт буенча үзәк китапханә бинасында оештырыла. Ике көн элек кенә узган кабул итүгә җиде кеше килде. Әлбәттә, аларның һәркайсы район башлыгына үзен борчыган сорау белән мөрәҗәгать итте. Гомумән алганда, үтенеч-гозерләр мәшгульлек, торак-коммуналь, транспорт хезмәте, инвалид балага матди ярдәм күрсәтү һәм башкалар иде.

Бер ханым мәшгульлек үзәге аша эшкә урнаша алмагач, проблемасын район башлыгы аша хәл итәргә уйлаган. Әлбәттә, аның соравы шул ук мәшгульлек үзәге аша каралды. Ханым бюджет оешмасына түгел, ә сәнәгать предприятиесенә эшкә урнашырга тели. Аңа ике предприятиедәге булган вакансияләрне белешеп, җитәкче белән әңгәмәгә барырга киңәш ителде.

Шәһәрнең Ленин урамы 27нче йортта яшәүче ике ханым капиталь ремонт, йорт ишегалдын төзекләндерү, балалар өчен уен мәйданчыгы булдыру мәсьәләсен күтәрде. Йортка капиталь ремонт 2012 елда үткәрелгән. Ул вакытта күп кенә эшләр башкарылмыйча калган. Аларга идарәче компания белән тыгыз элемтәдә булу киңәклеге, йортларга ремонт үткәрү тәртибе аңлатылды.

Икенче бер ханым Зәй автовокзалына транзит автобусларының бик азлары гына керүенә зарланды. Нурлат ягына бару проблема, элек вокзалга Самара автобусы керә иде, хәзер юк, диде. Җиңү проспекты 1/02 йортында яшәүче булара, ул йортка якын урнашкан тәүлек буе эшләүче "Каенкай" кибетенең әлеге йорттагылар өчен уңайсызлыклар тудыруын әйтте, закон нигезендә тыюлуга карамастан, төнлә исерткеч эчемлекләр сатыла, исерекләрдән тынычлык юк, алар йорт подъездына керәләр, диде.

Разиф Кәримов мөрәҗәгать итүчеләрнең барысын да игътибар белән тыңлап, кайберләренә җавапны шунда ук бирде, икенчеләрен өйрәнү, хәл итү өчен тиешле күрсәтмәләр бирде.

*Николай ШАМИОНОВ.*
*Автор фотосы.*

МӘКТӘП АВТОБУСЛАРЫ

# Балалар имин йөрсен

***Авыл-бистәләрдән балаларны мәктәпкә йөртү өчен мәктәп автобусы маршрутлары эшли. Бу бер авылдан икенче авылга укырга йөрүчеләр өчен аеруча уңайлы. Быелгы уку елында районда 17 автобус расланган машрут буенча йөри.***

Уку елы башланыр алдыннан мәктәп автобуслары район башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов җитәкчелегендәге махсус комиссия тарафыннан җитди тикшерү узып кабул ителде. Район ЮХИДИ бүлеге башлыгы Илдар Вәлиуллин автобусларның техник торышына, маршрут уза торган юлларга юл билгеләренең куелышына, кагыйдәләрнең үтәлешенә бик җентекле якын килде.

- Агымдагы елда барлыгы 481 баланы мәктәп автобусларында йөртәбез. Һәр автобусның маршруты билгеле, аларда балаларны барлау эшен укытучылар күзәтә. Уку елы дәвамында районга тагын бер яңа автобус кайтырга тиеш, бу инде өстәмә рәвештә мәктәп автобусы маршруты барлыкка килә диган сүз, - ди мәгариф идарәсе башлыгы Сергей Кузнецов.

Мәктәп автобусларын йөртүчеләргә килгәндә, алар - нигездә стажлы, озак еллар нәкъ менә автобусларда эшләүче тәҗрибәле хезмәткәрләр.

-Узган елларда автобусларның торышына, аларны йөртүчеләргә карата әти-әниләрдән дә, мәктәп директорларыннан да шикаятьләр булмады. Быел да шушы формада эшләү кирәк. Иң мөһиме - балаларны юлларда хәвеф-хәтәрсез йөртү, шуңа да һәр йөртүченең медицина күзәтүе узуы, юлга автобусларның һәр көн тиешле таләпләргә җавап биргән халәттә чыгуы - көнүзәк мәсьәлә. Без - өлкәннәр балалар өчен җаваплы, моны мәктәп автобуслары йөрешенә бәйле булган һәркем аңларга, һәр таләпне үтәргә тиеш, -дип катгый искәртте Илнар Хафизов.




*Энҗе ӘГЪЛӘМОВА.*
*Айгөл Яруллина фотосы.*

«ИШЕГАЛДЫ БӘЙРӘМЕ»

# «Йортыбыз танымаслык булып үзгәрде»



Зәйдә күпфатирлы йортларда зур төзекләндерү эшләре башкаргач, "Ишегалды бәйрәме" уздыру гадәте бар. Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау программасы кысаларында агымдагы елда 17 йортта зур төзекләндерү эшләре алып барылды. Алар - Җиңү проспектының 1/06, 1/11, 1/21, 16; Жуков урамының 9, Заречная урамының 20, Комсомол урамының 67, Крупская урамының 1, Ленин урамының 16, Октябрь урамының 16, Беренче Май урамының 3, Энергетиклар урамының 8, Яшьлек урамының 7а, Сарсаз-Багражда Яшьләр урамының 1, 2, 3нче йортлары.

- Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау үз вакытында башланып, тиешле вакытка сыйфатлы итеп башкарылды. Киләсе елда да әлеге программа гамәлдә, ремонтланасы йортларны барлау бара, - ди башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Николай Нифатов.

Агымдагы елның 1 мартында башланган капиталь ремонт эше 15 августка тәмамланды. Барлык эшләр техника куркынычсызлыгы таләпләрен саклап һәм җитештерү технологиясен бозмыйча башкарылды. Эш сыйфаты күзәтчелек органнары һәм ТР ТКХ фонды күзәтүендә барды.

Атна башында Энергетиклар урамы 8, Крупская урамы 1, Комсомол урамы 67нче йортлары ишегалдында әлеге йортларны зур төзекләндерүдән соң, "Ишегалды бәйрәме" узды.

-Энергетиклар урамының 8нче йортына ел башында килеп урнашкан идек. Йортның фасады иске, тузган булуы бер дә күңелгә хуш килмәгән иде. Капиталь ремонттан соң ул танымаслык булып үзгәрде. Сөенечебезнең чиге юк, - ди Елена Савельева.

Әлеге йортлар фасадлары юеш алым белән ремонтланды, буяулар купмый торган, зәвыклы. Энергетиклар урамының 8нче йорты исә зур төзекләндерү эшләре алып барылган "Энергетик" Мәдәният сарае белән төстәш, аны тулыландырып тора.

"Ишегалды бәйрәме" җылы һәм ихтә калырдай итеп оештырылды. Әлеге йортларда яшәүчеләрне район башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов тәбрикләде, ул районда алып барылучы масштаблы төзелеш эшләре, аерым алганда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт турында бәян итте. "Уңайлы йорт" торак милекчеләре ширкәте рәисе Сергей Крыловның да әйтер сүзе күп булды. Өлкән буын исеменнән сүз алган Рәфкать Аптикашов та йортларның матурлануына, җылынуына сөенүен белдерде. Ул әлеге йортларның берсендә шактый еллар гомер итә, балалар үсеп башлыкүзле булды, хәзер оныклар үсә, ди. Төзекләндерү эшләрен әлеге йортларда "Заинская кровля" һәм "Самур" оешмасы төзүчеләре башкарган. Бәйрәм барышында аларга район башкарма комитеты җитәкчесе Рәхмәт хатлары тапшырылды.

Күрше күршесен белү дә кирәк, йортта яшәүчеләр берберсе белән аралашты, хәлаххвәл белеште.

- Әлеге йортларның берсендә 90нчы елдан бирле гомер итәм. Күршеләрем туганнар кебек хәзер, кайгы-шатлыкларны уртаклашып яшибез, - ди Фәния Әгъзамова.

Бәйрәмдә ул күршеләр темасына шигырь дә сөйләде. Чарада ветераннарның урыны түрдән булды. Юбилярлар, беренче класска укырга баручылар да читтә калмады. "Энергетик" Мәдәният сарае сәнгать коллективлары әзерләгән концерт программасы аны тагын да баетты. Ә балалар өчен яшьләр эшләре идарәсе активистлары төрле кызыклы, мавыктыргыч уеннар оештырды. Бәйрәмне Фәннүр Миннекәев белән Нина Шатрилова алып барды. Үзәк китапханә хезмәткәрләре оештырган Зәй турындагы күргәзмә яныннан беркем дә битараф узмады.

Бу көннәрдә Энергетиклар урамының 8нче йорты ишегалды юлы да төзекләндереләчәк. Зур ремонтлардан соң әлеге йортларда яшәүчеләр алдында алга таба аларның матурлыгын, төзеклеген, бөтенлеген саклау вазгыяте тора. Матурлык, тәртип һәрберебез өчен кирәк.

*Рәзимә КАШАПОВА.*